

Раиф Мәрданов
Тарихта тибрәлгән
ТӘБӘРЛЕ

# Мотаhара Шафикова-Гәрәева шигыре
# “Туган авылым Тәбәрле”

Туган авылым туфрагына басып йөрдек,
Әби-бабай диңгезендә уйнап үстек.
Җырлый-җырлый болынында печән чаптык,
Кырларында тырышып эшләп, тирләр түктек.

Тау астының салкын чишмә суын эчтек,
Шуңа күрә сау-сәламәт булып үстек.
Урманыннан җиләк-җимешләрен җыеп,
Кирәк икән, утынын да барып кистек.

Яшьлегемә кире кайтып уйлаганда,
Сине сагынам, туган авылым, кырларыңны.
Мәңгегә дә кабатланмас узган гомерем,
Җырлыйм хәзер искә алып җырларыңны.

Искә төшә Чаж урманы торналары,
Сайраганы язгы сабан тургайлары,
Искә төшә Иван абай тегермәне,
Җиләк-җимеш, баланы һәм бөрлегәне.

Сәет елгасы суларын бик күп эчтек,
Әсән тарлавы буенда уйнап үстек,
Төпи тавы безнең өчен ана булды,
Чана тарткан бала-чага шунда тулды.

Искә төшә Качкын төбәк чокырлары,
Шунда барып бәпчек-көпшә җыюлары.
Һич онтылмый Мукшур якның болыннары,
Ак чәчкәгә төрелгән шомыртлары.

Искә төшә Тәбәрленең авыл халкы,
Килен-киртәк, малай-шалай, яше-карты.
Бик күп җиләк-җимешләрне биргән
Онтылмыйсың әрәмәбез – «Шәрәфи арты».

Их! Сабый чак, еракларда калдың мени?
Төнге учак кебек дөрләп яндың мени?
Шигырь яздым авылымны искә алып,
Җырлар идем сине һәркөн җырга салып.

# ТӘБӘРЛЕ ЮКӘЛӘРЕ

Ф.Гомәрова сүзләре, Гафият Нигматуллин көе



**Бай тарихлы авылымны**
**Бизиләр төз юкәләр.**
**Киң, якты урамнарында**
**Рәхәтләнеп үсәләр.**
**Тәбәрленең юкәләре -**
**Матур йола үрнәге.**
**Яшь баласы туган көнне.**
**Утырткан әткәләре.**
**Юкә чәчәк аткач, авыл**
**Бал исе белән тула.**
**Юлчылар сокланып уза**
**Олы юл урамына.**
**Җәйләрен рәхәт ял итү**
**Юкә күләгәсендә.**
**Каз бәбкәләре тәгәри**
**Хәтфә үлән өстендә.**





# ТӘБӘРЛЕ ЮКӘЛӘРЕ

Ф.Гомәрова сүзләре, Гафият Нигматуллин көе



Бай тарихлы авылымны
Бизиләр төз юкәләр.
Киң, якты урамнарында
Рәхәтләнеп үсәләр.
Тәбәрленең юкәләре -
Матур йола үрнәге.
Яшь баласы туган көнне.
Утырткан әткәләре.
Юкә чәчәк аткач, авыл
Бал исе белән тула.
Юлчылар сокланып уза
Олы юл урамына.
Җәйләрен рәхәт ял итү
Юкә күләгәсендә.
Каз бәбкәләре тәгәри
Хәтфә үлән өстендә.





